ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.10.2022 ел Баулы №216

Россия Федерациясе Кораллы
Көчләренә мобилизация буенча
хәрби хезмәткә чакырылган хәрби
хезмәткәрләр гаиләләренә социаль
булышлык һәм социаль ярдәм
чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:

- Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү;

- шәһәрнең һәм районның гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларын ике тапкыр (иртәнге аш, төшке аш) түләүсез кайнар азык белән тәэмин итү;

- Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына чираттан тыш кертүне тәэмин итү.

2. МКУ «Отдел образования Бавлинского муниципального района Республики Татарстан»:

2. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ:

- әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән ярдәм (ташламалар) чараларын хәрби комиссариатның мәгариф оешмасы укучысының (тәрбияләнүчененең) ата-анасы (законлы вәкиле) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу турында белешмәсе нигезендә бирергә;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта ярдәм итү чараларының (ташламаларның) гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатыннан хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне булдыру.

3. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән булган тәрбияләнүчеләрне/укучыларны Баулы муниципаль районы мәгариф оешмаларында тәрбияләүне финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар гражданның 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу вакытында кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
җитәкчесе вазифаларын
башкаручы

И.И. Хөснуллина